ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07 март 2018ел № 1180

Башкарма комитетның 2013 елның 27 сентябрендәге 5863 нче карары белән расланган Мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Уставының 41 маддәсе, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24, 5.25 пунктлары нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2013 елның 27 сентябрендәге 5863 нче карары белән (Башкарма комитетның 2014 елның 17 февралендәге 944 нче, 2015 елның 18 ноябрендәге 6571 нче, 2016 елның 29 апрелендәге 2159 нчы, 2017 елның 6 апрелендәге 1955 нче карарлары редакциясендә) расланган Мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү тәртибенә, 8 пунктны түбәндәге эчтәлектәге өченче абзац белән тулыландырып, үзгәрешләр кертергә:

«Вәкаләтле органда мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыра торган белем бирү оешмаларында баланы карау һәм тәрбияләү өчен ата-ана түләвенең бер өлешенә компенсация алуга хокукын раслаучы мәгълүматлар булган очракта, әлеге компенсация яңа срокка гариза бирүченең мөрәҗәгатеннән башка билгеләнә.»

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы вазыйфаларын башкаручы И.А. Сәгыйдуллинага, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин